**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Яңасала авыл җирлеге Олы Яңасала авылында**
**гражданнарга үзара салым кертү турында**
**КАРАРы**

6 нчы декабрь 2022 ел № 1

“Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, “Татарстан Рес публикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Яңасала авылында гражданнар җыены **карар итте** :

1.Үзара салым 2023 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Яңасала авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000,00 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәгеләрне үтәү буенча юнәлтергә:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш белән чокырларны ямау, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- җәйге чорда территорияне чабу(килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, чапкыч сатып алу);
-янгын сүндерү машинасын карап тоту ( ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
- кышкы чорда территорияләрне кардан чистарту (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
- зират территориясен ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу);
- сусаклагычны (су савытын) чистарту, юу (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерү:

- ТР Кама Тамагы районы Олы Яңасала авылы Үзәк ур., 1;
- ТР Кама Тамагы районы Шәпкә авылы,Клуб урамы, 14 йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче ,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Яңасала авыл җирлеге
башлыгы: И.Х.Шиһабеев